КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 октябрь г.Казань № 1216

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм файдалану» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 21 июль, 521 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 950 нче; 2015 ел, 6 май, 329 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2015 ел, 1 декабрь, 910 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 383 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 980 нче; 2017 ел, 27 февраль, 117 нче; 2018 ел, 5 май, 326 нчы; 2018 ел, 27 сентябрь, 866 нчы; 2019 ел, 27 июль, 628 нче; 2020 ел, 8 июнь, 472 нче; 2020 ел, 12 ноябрь, 1013 нче; 2021 ел, 4 май, 304 нче; 2021 ел, 9 октябрь, 966 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы; 2022 ел, 18 апрель, 364 нче; 2022 ел, 18 июль, 685 нче, 2023 ел, 17 май, 605 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында"

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба - дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта «тиешле финанс елына» сүзләрен «чираттагы финанс елына һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга, «Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Бу карарга кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары һәм актларның аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге карары 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1083 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 3 октябрь, 1216 нчы карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

«Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик өстенлекләр

I. Әйләнә-тирә мохитне саклау, экологик иминлек һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә агымдагы халәтне бәяләү

Татарстан Республикасы Россиянең аеруча икътисадый һәм сәнәгый үсеш алган төбәкләреннән берсе булып тора. Татарстан территориясендә Россиядә иң эре булган нефть чыгару, нефть химиясе, машина төзелеше үзәкләре урнаша. Татарстан Республикасының шактый зур территориясендә антропоген йөкләнешнең югары булуы атмосфера һавасының, җир өсте һәм җир асты суларының, туфракның химик матдәләр белән пычрануы белән бәйле.

Республиканың экологик торышына хәзерге вакытта «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасында, Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерында җитештерүләр комплексын үстерү буенча тормышка ашырыла торган эре проектлар, Менделеевск шәһәренең сәнәгать зонасы территориясендә «Аммоний» акционерлык җәмгыятенең аммиак, метанол һәм карбамид җитештерү комплексын төзү, «АлмА» махсус икътисадый зонасын үстерү киеренкелек кертә.

Атмосфера һавасы

«Татарстан Республикасының гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе мәгълүматлары буенча, Казанда һәм Чаллыда һаваның пычрану дәрәҗәсе югары булуы белән характерлана, Түбән Кама шәһәрендә «югары» буларак характерлана.

Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохите торышын күзәтүнең территориаль системасын үстерү кысаларында бердәм цифрлы киңлектә 17 стационар атмосфера һавасының пычрануын автомат контрольдә тоту станциясе

һәм 6 күчмә экологик лаборатория мәгълүматлары берләштерелде. Бердәм серверда тупланган мәгълүматлар барлык контроль станцияләреннән заманча цифрлы чишелешләр кулланып эшкәртелә.

Атмосфера һавасы торышын күзәтүнең территориаль системасы атмосфера һавасы пычрануының җыелма исәп-хисапларына нигезләнгән атмосфера һавасы торышының исәп-хисап мониторингы системасы белән тулыландырылды. 2023 елга карата атмосфера һавасы торышының исәп-хисап мониторингы системасы Казан, Түбән Кама һәм Алабуга шәһәрләрендә эшли торган калдыклар чыгару чыганаклары буенча актуаль мәгълүматларны үз эченә ала.

## Су ресурслары

Татарстан Республикасында су өслегенең гомуми мәйданы 4,4 мең кв.километр, яки республика территориясе мәйданының 6,4 процентын тәшкил итә. Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының төп кушылдыкларының 73 бассейны исәпләнә, гомуми гидрографик челтәр, вак һәм кибеп баручы су объектларын исәпкә алып, 20,0 мең километрдан артык озынлыктагы 4 100 су агымын үз эченә ала, даими агымлы 5 210 елга, 8 073 күл, 7 375 сазлык, 3 134 чишмә исәпләнә. Дәүләт статистикасы мәгълүматларына караганда, 1968 елдан башланган чор дәвамында республика территориясендә табигый һәм антропоген сәбәпләр буенча, шул исәптән ләмләнү аркасында 1 681 күл юкка чыккан.

Татарстан Республикасы өске су объектларының гидрохимик торышының динамикасын бәяләү өчен мониторинг күзәтүләре хәзерге вакытта 64 су объектында 115 күзәтү пунктында гамәлгә ашырыла.

Антропоген пычрануның килеп чыккан дәрәҗәсе су объектлары деградациясен китереп чыгара торган төп сәбәпләрнең берсе булып тора. Иң киеренке экологик вәзгыять Идел елгасы бассейнында күзәтелә: Идел елгасының су ресурсларына антропоген йөкләнеш Россия буенча уртача күрсәткечләрдән 8 тапкыр югарырак. 2019 елдан «Экология» милли проектының «Иделне савыктыру» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы чикләрендә Идел елгасында пычратылган агымлы сулар күләмен киметүгә һәм әйләнә-тирә мохиткә куркыныч янаучы ике объектны юкка чыгаруга (рекультивацияләүгә) юнәлтелгән чаралар гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының төче җир асты суларының фаразланган ресурслары күләме тәүлегенә 5,46 млн. куб метр тәшкил итә. Бер кешегә, эчәргә яраклы һәм техник суларны кертеп, 1 тәүлеккә 1,45 куб.метр җир асты төче сулары туры килә. Республика территориясе буенча җир асты төче суларының фаразланган ресурслары тигез бүленмәгән. Бигрәк тә Чүпрәле, Чирмешән, Әтнә, Баулы һәм Әлмәт муниципаль районнары фаразланган ресурслар белән аз тәэмин ителгән.

Татарстан Республикасы халкын эчәргә яраклы чиста су белән тәэмин итү беренчел чираттагы социаль бурычларның берсе булып тора. Республика территориясендә 2022 елның 01 октябренә 522 чыганак һәм җир асты сулары ятмалары кишәрлекләре ачыкланды һәм тикшерелде, алар буенча расланган запаслар тәүлегенә 2 383,873 мең куб метр тәшкил итә, шуларның 2 336,727 мең куб метр (402 ятма) - эчә торган җир асты сулары запаслары. 2022 елның 01 октябре

мәгълүматлары буенча республикада бер кешегә җир асты суларының разведка белән тәэмин ителеше тәүлегенә 0,60 мең куб метр тәшкил итте.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы территориясендә интенсив хуҗалык эшчәнлеге йогынтысы астында җир асты суларын пычрату чыганаклары актив формалаша, җир асты төче суларының сыйфаты начарланган су алу җайланмаларының саны арта. Мондый хәвефле тенденция җир асты суларын юкка чыгудан һәм пычранудан саклауны һәм мониторинглауны оештыру зарурлыгын билгели.

Суларның тискәре йогынтысы

Мониторинг мәгълүматларына караганда, экзоген процесслар, абразив һәм ишелү процесслары Куйбышев сусаклагычының уңъяк өлешендә киң таралган. Татарстан Республикасы чикләрендә Куйбышев сусаклагычының яр буе линиясе озынлыгы 1 392 километр тәшкил итә, шуның 210 километры абразив һәм ишелү процессларына актив дучар. Әлеге процесслар аркасында республика икътисадына ел саен 2 млрд.сумнан артык зыян салына.

2023 ел мәгълүматлары буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы территориясендә федераль милектәге, Татарстан Республикасы милкендәге, муниципаль милектәге 926 гидротехник корылмадан һәм хуҗасыз гидротехник корылмалардан 168 потенциаль куркыныч гидротехник корылма буларак бәяләнә.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматы буенча, 2023 елда Татарстан Республикасы территориясендә язгы ташуны үстерүнең иң начар сценарие нигезендә су басу (су басу) мөмкинлеге булган зонада 220 торак пункт булырга мөмкин. Башлангыч мәгълүматларга караганда, җирлекләр чикләрендә 2,8 мең километр озынлыктагы яр буе линиясе участокларында суларның тискәре йогынтысы куркынычы астында 186,4 мең кеше исәпләнә.

Минераль-чимал базасы

Татарстан Республикасы алга киткән минераль-чимал комплексы белән характерлана. Татарстан җир асты байлыкларының товар кыйммәте нефть, табигый битумнар ятмалары һәм руда булмаган каты файдалы казылмаларның ликвидлы төрләре белән билгеләнә. Аларның күбесе чыгарыла, башкаларын үзләштерү якын киләчәктә икътисадның ихтыяҗына карап гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасының җир асты байлыкларында шактый киң спектрдагы гомумтаралган файдалы казылмалар бар, алар нигезендә җитештерү оештырылган һәм республика икътисадының төзелеш һәи силикат комына, баетылган ком-гравий катнашмасына, керамик кирпечкә, керамзитлы чуерташка, төзелеш известенә, төзелеш вак ташына, известьле онга ихтыяҗы тулысынча яки өлешчә тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы территориясендә 1 100 ятма һәм руда булмаган каты файдалы казылмалар күренешләре ачыкланды һәм тикшерелде, аларның төп өлеше гомумтаралган файдалы казылмаларга карый. Республика балансында гомумтаралган

файдалы казылмаларның 13 төре чыгарыла торган 480 урын исәпкә алынды, шуларның 30 проценттан артыгы эксплуатациягә җәлеп ителде.

Икътисад тармаклары ихтыяҗларын минераль чимал белән тәэмин итү өчен эшләп торучы предприятиеләрнең чимал базасын киңәйтергә дә һәм аны яңа җитештерүләрне оештыру максаты белән торгызырга да кирәк. Бу чараларны тормышка ашыру җир асты байлыкларының бүленмәгән фонды объектларын, шулай ук расланган файдалы казылмалар запаслары булмаган ятмаларны лицензияләүгә һәм үзләштерүгә әзерләү белән бәйле.

Куркыныч геологик процессларның (ишелү, су юып ашау, чокыр һәм үзән эрозиясе) халык хуҗалыгы объектларына йогынты ясавы республика территориясендә аларның үсү һәм таралу закончалыкларын исәпкә алуны, куркыныч экзоген геологик процесслар активлыгы фаразларын эшләүне таләп итә.

## Калдыклар

Ел саен Татарстан Республикасында 10 млн.тоннадан артык җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килә. Җыелган сәнәгать һәм көнкүреш калдыкларының гомуми күләменнән икенчел ресурслар буларак бары 10 процент кына файдаланыла. Хуҗалыкта әйләнештә йөртү өчен югары ликвидлы һәм табыш бирә торган калдыклар, башлыча, кара һәм төсле металлар ватыклары һәм калдыклары гына җәлеп ителә.

## Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян

Татарстан Республикасының интенсив социаль-икътисадый үсеше, табигый ресурсларны интенсив индустриальләштерү һәм экстенсив чыгару процесслары әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектлары барлыкка килүнең төп сәбәпләренә әверелде. «Чиста ил» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында 2017 елдан 2023 елга кадәр республика территориясендә әйләнә-тирә мохиткә җыелган иң куркыныч ике объект һәм шәһәр чикләрендә санкцияләнмәгән өч чүплек юк ителде.

## Биологик төрлелек

Биологик төрлелекне саклап калу, торгызу һәм өйрәнү максатларында Татарстан Республикасы мәйданының 7 процентында махсус саклanучы табигать территорияләре булдырылды, табигать комплексларын, ландшафтларны һәм биологик төрлелекне саклау һәм торгызу өчен уңай шартлар тәэмин ителде.

2020 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасының табигать-тыюлык фонды 465,109 мең гектар гомуми мәйданлы барлык дәрәҗәләрдәге 193 махсус саклана торган табигать территорияләреннән, шул исәптән 423,135 мең гектар мәйданлы төбәк әһәмиятендәге 187 махсус саклана торган табигать территорияләреннән гыйбарәт.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында региональ әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрендә экологик туризмны кертү һәм үстерү, махсус сакланылучы табигать территорияләрен республиканың социаль-икътисадый үсеше өлкәсенә интеграцияләү өчен шартлар тудыру күздә тотыла.

## Аучылык ресурслары

2023 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасының аучылык биләмәләре мәйданы – 6 309,4 мең гектар, хайваннар дөньясыннан озак вакытлы файдалану өчен бирелгән аучылык биләмәләре мәйданы – 4 239,2 мең гектар (67,19 процент), һәркем файдалана алган аучылык биләмәләре мәйданы 1 857,5 мең гектар (29,44 процент) тәшкил итә.

Татарстан Республикасында гомуми мәйданы 212,7 мең гектар булган биш аучылык заказнигы эшли, аларда махсус хокукый режим билгеләнгән, терлекләрдән файдалану чикләнгән, ел саен аларның санын исәпкә алу уздырыла. 2023 елның 1 гыйнварына аучылык ресурслары санын мониторинглау аучылык ресурсларының 81 төре буенча гамәлгә ашырыла.

## Мәгълүмати тәэмин итү һәм экологик белем бирү

Гомумән алганда, Татарстан өчен тармакларны цифрлы трансформацияләү мөһим момент булып тора. Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасының экологик картасы» геомәгълүмат системасы булдырылды, аның составына 26 ярдәмче система, шулай ук аларны ачыклау урынында административ хокук бозулар турында материалларны рәсмиләштерү өчен мобиль кушымта керә. Күрсәтелгән система ведомствоара электрон документ әйләнеше бердәм системасы, «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасы белән интеграцияләнгән.

Экологик белем һәм агарту массакүләм коммуникация технологияләрен, ысулларын һәм каналларын үстерүне исәпкә алып, җәмгыять һәм икътисадны тотрыклы үстерүне тәэмин итә торган нәтиҗәле корал булып тора.

Татарстан Республикасы халкына экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендәге тенденцияләр, үзгәрешләр һәм планнар турында объектив һәм оператив мәгълүмат бирү татарстанлыларның экологик юнәлешле фикерләвен формалаштыруның мөһим шарты булып тора.

## II. Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте өстенлекләрен һәм максатларын тасвирлау

Татарстан Республикасы дәүләт программасының өстенлекләре Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсеше илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указына, Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең экологик иминлеге стратегиясе турында» 2017 елның 19 апрелендәге 176 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең экологик иминлеге стратегиясенә, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе милли иминлеге стратегиясенә, Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2012 елның 30 апрелендә расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең экологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәте нигезләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең

2024 елга кадәрге чорда һәм 2030 елга кадәрге план чорына Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм планына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 25 гыйнварындагы № 84-б номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр җитештерү һәм куллану калдыкларын эшкәртү, утильләштерү һәм зарарсызландыру сәнәгатьне үстерү стратегиясенә, шулай ук «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясенә (алга таба - Страгтегия-2030) туры килә.

Социаль-икътисадый бурычларны баланслы хәл итү, мохитнең экологик иминлеге һәм шәхеснең һәм җәмгыятьнең тормыш өчен мөһим мәнфәгатьләре өчен куркынычларны киметү һәм Татарстан Республикасының конкуренциягә сәләтлелеген арттыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт экология сәясәте стратегиясен үстерүдә Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләренең максатлары, структурасы һәм системасы эшләнде.

1 нче максат «Татарстан Республикасы гражданнарының экологик иминлек дәрәҗәсен арттыру» түбәндәге күрсәткечләргә ирешү белән характерлана:

Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохит сыйфатын 108,3 процент дәрәҗәсендә тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохиткә тупланган зарарның ике объектын, шәһәрләр чикләрендә рөхсәтсез өч чүплекне һәм әйләнә-тирә мохиткә янау куркынычы тудыра торган әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянны бетерү юлы белән Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны бетерү;

каты коммуналь, шул исәптән эшкәртүне (сортировкалауны) үткән калдыкларны күмүне киметү исәбенә халыкка экологик йөкләнешне 99,1 процент күләмендә киметүне тәэмин итү.

Гражданнарның экологик фикерләвен һәм экологик культурасын булдыру шарты белән, Татарстан Республикасы икътисадын экологик яктан тотрыклы, динамик үстерү, уңайлы әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану нигезендә Татарстан Республикасы халкының тормыш сыйфатын тәэмин итүнең төп бурычларыннан берсе булып тора.

2 нче максат «Татарстан Республикасы табигать ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану» түбәндәге күрсәткечләргә ирешү белән характерлана:

җир асты байлыклары турында геологик мәгълүмат белән Татарстан Республикасы икътисадын тәэмин итү һәм Стратегия-2030 каралган күләмнәрдә файдалы казылмалар запасларын торгызу;

2024 ел ахырына территорияләрдә яшәүче, сулар йогынтысына дучар булган 52,6 меңнән артык кешенең якланганлыгын тәэмин итү;

2024 ел ахырына якында 303,4 меңнән артык кеше яшәгән су объектлары янында яшәүнең экологик шартларын яхшырту өчен су объектларын саклап калу һәм торгызу;

2026 елга кадәр план чорына биологик төрлелекне саклап калу, торгызу һәм алардан нәтиҗәле файдалану, шул исәптән аеруча саклана торган табигать территорияләренең мәйданы өлешен 7 процентка кадәр арттыру юлы белән.

consultantplus://offline/ref=7A451FA9CA1CDD2D1FE506B7572F67D74CCAC8C7BC92561429726B9E0E06D7E546B383532551C1B5EDDF95946B937EB28391C0871304C11AjAS6LРоссия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 22 декабрендәге 2914-б номерлы боерыгы белән расланган 2035 елга кадәр Россия Федерациясенең минераль-чимал базасын үстерү стратегиясе бурычлары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә минераль-чимал базасын үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре булып Татарстан Республикасы территориясенең геологик өйрәнелгәнлеген арттыру, төзелгән минераль-чимал базасыннан нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү, җир асты суларын торгызу һәм саклау, җир асты байлыкларыннан файдалануны мәгълүмати тәэмин итү системасын яхшырту, мәгълүмат технологияләрен үстерү юлы белән Татарстан Республикасы минераль-чимал базасын мониторинглау һәм үстерүне системасын яхшырту, шул исәптән геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә автоматлаштырылган идарә системаларын кертү, эшкәртү, интерпретацияләү, алардан файдалану һәм файдалану исәбенә әлеге күрсәткечләрне бирүне тәэмин итү тора.

Су хуҗалыгы комплексын үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп максатлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

су объектларын халыкның экологик яктан уңай тормыш шартларын тәэмин итә торган хәлгә кадәр торгызу. Су объектларында су сыйфатын яхшырту халык тормышының югары стандартларына ирешүнең, уңайлы экологик шартлар булдыруның һәм Татарстан Республикасы халкының киләчәк буыннары мәнфәгатьләрен тәэмин итүнең мөһим шарты булып тора;

халыкның һәм икътисад объектларының су басудан һәм суларның башка тискәре йогынтысыннан саклануын тәэмин итү. Территорияләрнең табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклануын тәэмин итү Россия Федерациясенең тотрыклы икътисадый үсешенең һәм суларның тискәре йогынтысыннан мөмкин булган зыян күләмен киметүнең кирәкле шарты булып тора.

Биологик төрлелекне саклау өлкәсендәге төп өстенлекләр һәм максатлар түбәндәгеләр:

хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларына һәм аларның яшәү урыннарына аерым игътибар белән, табигый яшәү тирәлегендә озак вакыт табигать экология системаларын, күренеш төрлелеген саклауны тәэмин итү;

әйләнә-тирә мохитне саклауда һәм биологик төрлелекне саклауда граждан җәмгыятенең роле арту.

## III. Стратегик өстенлекләр, илкүләм максатлар һәм Стратегия-2030 максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программалары күрсәткечләре белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Әлеге Татарстан Республикасы дәүләт программасы Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең

2024 елга кадәрге чорда һәм 2030 елга кадәрге план чорына Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешүнең бердәм планы, шулай ук Стратегия-2030 белән билгеләнгән Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына һәм аларның максатчан күрсәткечләренә ирешүгә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы түбәндәге максатчан күрсәткечләргә ирешүгә юнәлдерелгән:

«Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» илкүләм максаты кысаларында

калдыкларны сортларга аеруны 100 процент күләмендә тәэмин итә торган каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең тотрыклы системасын булдыру һәм полигоннарга җибәрелә торган калдыклар күләмен 2 тапкырга киметү;

әйләнә-тирә мохиткә аеруча куркыныч тупланган зыян салу объектларын бетерү һәм су объектларын (Идел елгасын, Байкал һәм Телецкое күлләрен дә кертеп) экологик савыктыру;

Стратегия-2030 кысаларында Татарстан Республикасының ике стратегик максатын гамәлгә ашыруга:

«Кеше капиталы» (СМ-1): уңайлы әйләнә-тирә мохитне тәэмин итү аша Татарстан Республикасы гражданнарының югары сыйфатлы тормыш шартларын тудыру; гражданнарның экологик фикерләвен һәм экологик культурасын формалаштыру;

«Табигать ресурслары» (СМ-6): Татарстан Республикасы икътисадын тотрыклы үстерү кысаларында республиканың минераль-чимал базасыннан, су ресурсларыннан, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясыннан рациональ файдалануны җайга салу.

## IV. Дәүләт идарәсенең бурычлары, аларны әйләнә-тирә мохитне саклау, экологик иминлек һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалану өлкәсендә нәтиҗәле чишү ысуллары

1. “Татарстан Республикасы гражданнарының экологик иминлек дәрәҗәсен арттыру” максатына ирешү кысаларында дәүләт идарәсе бурычларына түбәндәгеләр керә:

табигатьтән файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәгән өчен региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) тәэмин итү, шулай ук иҗтимагый экология контроле системасын үстерү;

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитнең торышын күзәтүнең территориаль системасын үстерү, экологик мониторинг үткәрү;

шәһәрләр чикләрендә санкцияләнмәгән чүплекләрне һәм әйләнә-тирә мохиткә тупланган иң куркыныч объектларны, шул исәптән Идел елгасының хәвеф-хәтәр куркынычы яный торган әйләнә-тирә мохиткә тупланган 2 объектны бетерү;

каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең комплекслы системасын формалаштыру, моңа каты коммуналь калдыкларны күмүне киметү исәбенә халыкка экологик йөкләнешне киметүне дә кертеп;

Татарстан Республикасы халкының экологик культурасын булдыру.

2. “Татарстан Республикасы табигый ресурсларын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану” максатына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

республиканың гамәлдәге минераль-чимал комплексын саклап калу һәм үстерү;

күлләр һәм елгалар үзәннәре участокларын торгызу һәм экологик торышын яхшырту эшләре комплексын үткәрү;

суларның тискәре йогынтысына дучар булган территорияләрдә яшәүче халыкның яклануын тәэмин итү;

аучылык хуҗалыгының ресурс базасын яхшырту һәм аучылык ресурслары санын арттыру;

үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм исәпкә алу, махсус сакланылучы табигать территорияләре системасын үстерү.

# «Татарстан Республикасы әйләнә-тирә мохитен саклау, табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Татарстан Республикасы дәүләт программасы паспорты

## 1. Төп нигезләмәләр

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы дәүләт программасы кураторы | Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасының җаваплы башкаручысы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасының ярдәмче башкаручылары | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;<br>Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты;<br>«Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;<br>«Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру чоры | 2014 – 2026 еллар, шул исәптән:<br>I этап: 2014 – 2023 еллар;<br>II этап: 2024 – 2026 еллар |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары | Татарстан Республикасы гражданнарының экологик иминлеге дәрәҗәсен арттыру.<br>Татарстан Республикасының табигать ресурсларын саклау һәм рациональ файдалану; |
| Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыруның бөтен чорында финанс белән тәэмин ителеш күләмнәре | I этап: 21 594 708,0 мең сум;<br>II этап: 4 747 619,8 мең сум |

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары, Стратегия-2030, Россия Федерациясе дәүләт программасы, Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатлары белән бәйләнеш | Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешүгә юнәлдерелгән:<br>1) «Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» 2030 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына:<br>калдыкларны сортларга аеруны 100 процент күләмендә тәэмин итә торган каты коммуналь калдыклар белән эш итүнең тотрыклы системасын булдыру һәм полигоннарга җибәрелә торган калдыклар күләмен 2 тапкырга кимету;<br>әйләнә-тирә мохиткә аеруча куркыныч тупланган зыян салу объектларын бетерү һәм су объектларын (Идел елгасын, Байкал һәм Телецкое күлләрен дә кертеп) экологик савыктыру;<br>2). Татарстан Республикасының ике стратегик максаты: (СМ-1) «Кеше капиталы», (СМ-6) «Табигать ресурслары»;<br>3) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирә мохитне саклау» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 326 номерлы карары белән расланган «Әйләнә-тирә мохитне саклау» Россия Федерациясе дәүләт программасы максатларына;<br>4) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 322 номерлы карары белән расланган «Табигать ресурсларын торгызу һәм алардан файдалану» Россия Федерациясе дәүләт программасы максатларына; |

## 2. Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткеч дәрәҗәсе | Арту / кимү билгесе | Үлчәү берәмлеге (Үлчәү берәмлекләре гомумроссия классификациясе буенча) | База күрсәткече | | Еллар буенча күрсәткеч әһәмияте | | | Документ | Күрсәткечкә ирешү өчен җаваплы | Илкүләм максатлар, Стратегия-2030 максатлары күрсәткечләре белән бәйләнеш | Муниципаль берәмлектә гамәлгә ашыру билгесе | Мәгълүмат системасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | күрсәткече | елы | 2024 | 2025 | 2026 | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| Татарстан Республикасы гражданнарының экологик иминлеге дәрәҗәсен арттыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Әйләнә-тирә мохитнең сыйфаты | Татарстан Республикасының югары вазыйфаи затлары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткеч | арта бара торган | процент | 104,2 | 2023 | 108,3 | 108,3 | 108,3 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-р номерлы боерыгы белән расланган 2024 елга кадәр чорга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм план (алга таба - Россия | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | «Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» илкүләм максаты кысаларында шәһәрләр чикләрендә ликвидацияләнгән чүплекләр саны; әйләнә-тирә мохиткә зарарлы тупланган иң куркыныч | юк | бердәм ведомствоара мәгълүмати-статистик система (алга таба - БВМСС) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | (алга таба - ЮВЗ) | | | | | | | | Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы) | | объектлар саны, арта барган нәтиҗә; Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыянның юкка чыгарылган һәм изоляцияләнгән Идел елгасына куркыныч тудыручы объектлары саны, арта барган нәтиҗә | | |
| 2. | Барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында күмүгә җибәрелгән, шул исәптән эшкәртелү (сортларга аеру) узган каты коммуналь калдыклар өлеше | илкүләм проект (алга таба – ИП) | кими бара торган | процент | 99,1 | 2023 | 99,1 | - | - | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | «Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» илкүләм максаты кысала-рында калдык-ларны сортларга аеруны 100 процент күләмендә тәэмин итә торган каты коммуналь кал-дыклар белән эш итүнең тотрыклы системасын бул-дыру һәм полигон-нарга җибәрелә торган калдыклар күләмен ике тапкырга киметү | юк | БВМСС |
| 3. | Барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында каты коммуналь калдыкларны аерып җыю һәм эшкәртү (сортларга аеру) нәтиҗәсендә аерылган һәм утилизацияләүгә җибәрелгән калдыклар өлеше | ИП | арта бара торган | процент | 0,9 | 2023 | 0,9 | - | - | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | | юк | БВМСС |
| 4. | Барлыкка килгән каты коммуналь калдыкларның гомуми массасында эшкәртүгә (сортировкалауга) җибәрелгән каты коммуналь калдыклар өлеше | ИП | арта бара торган | процент | 21 | 2023 | 21 | - | - | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | | юк | БВМСС |
| Татарстан Республикасының табигать ресурсларын саклау һәм рациональ файдалану; | | | | | | | | | | | | | | |
| 5. | Елга үзәннәренең чистартылган участоклары озынлыгы | ИП | арта бара торган | километр, мең метр | 21,3 | 2023 | 21,3 | 21,3 | 21,3 | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 1 октябрендәге 2765-б номерлы боерыгы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | «Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» илкүләм максатын гамәлгә ашыру кысала-рында: су объект-ларын, шул исәптән Идел, Байкал һәм Телецк күлләрен дә | юк | БВМСС |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | кертеп, экологик савыктыру | | |
| 6. | Инженерлык яклавының һәм ярларны ныгытуның яңа һәм реконструкцияләнгән корылмаларының озынлыгы | илкүләм проект составына керми торган федераль проект (алга таба – ИП керми торган ФП) | арта бара торган | километр | 0,58 | 2023 | 0,58 | 0,58 | 0,58 | Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең экология иминлеге стратегиясе турында» 2017 елның 19 апрелендәге 176 номерлы Указы (алга таба - Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 19 апрелендәге 176 номерлы Указы) | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | «Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» илкүләм максатын гамәлгә ашыру кысаларында: су объектларын, шул исәптән Идел, Байкал һәм Телецк күлләрен дә кертеп, экологик савыктыру | юк | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәгълүматы (алга таба - ТР Экология министрлыгы) |
| | | Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – ДП) | арта бара торган | километр | 24,02 | 2023 | 24,02 | 24,02 | 24,02 | | | | | |
| 7. | Торышы канәгатьләнерлек булмаган һәм куркыныч булган гидротехник корылмаларның куркынычсыз техник халәткә кертелгәннәре саны | ИП керми торган ФП | арта бара торган | данә | 2 | 2023 | 14 | 14 | 14 | Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 19 апрелендәге 176 номерлы Указы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | «Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» илкүләм максатын гамәлгә ашыру кысаларында: су объектларын, шул исәптән Идел, Байкал һәм Телецк күлләрен дә кертеп, экологик савыктыру | юк | ТР Экология министрлыгы мәгълүматы |
| | | ДП | арта бара торган | данә | 85 | 2023 | 85 | 85 | 85 | | | | | |
| 8. | Суларының тискәре йогынтысыннан яклауны арттыру чараларын үткәрү максатларында су объектларын чистарту эшләре дәвамлылыгы | ИП керми торган ФП | арта бара торган | километр | 9,27 | 2023 | 11,28 | 11,28 | 11,28 | Россия Федерациясе Президентының 2017 елның 19 апрелендәге 176 номерлы Указы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | «Тормыш өчен уңайлы һәм имин мохит» илкүләм максатын гамәлгә ашыру кысаларында: су объектларын, шул исәптән Идел, Байкал һәм Телецк күлләрен дә кертеп, экологик савыктыру | юк | ТР Экология министрлыгы мәгълүматы |
| | | ДП | арта бара торган | километр | 29,15 | 2023 | 29,15 | 29,15 | 29,15 | | | | | |
